| СОВЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2019ел Яңа Чүте авылы №118

Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Баулы муниципаль районы бюджетына Салих авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Салих авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Салих авыл җирлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына субсидияләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру очракларында Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә. Субсидияләр бирү шартлары Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге башкарма комитетының норматив-хокукый актлары белән (алга таба авыл җирлеге башкарма комитеты) билгеләнә.

2. Субсидияләр Салих авыл җирлеге Советының «Салих авыл җирлегенең тиешле финанс елына һәм план чорына бюджеты турында» гы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче-авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Баулы муниципаль районы бюджетына субсидияләрне бүлү Татарстан Республикасының Баулы шәһәр Советының «Салихово авыл җирлегенең тиешле финанс елына һәм план чорына бюджеты турында»гы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирүнең максатлары һәм тәртибе авыл җирлеге башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты арасында төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм аны тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны тормышка ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан район башкарма комитетына җибәрелә.

9. Килешү авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе һәм район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Район бюджетына бирелә торган субсидия күләме, муниципаль берәмлекне сайлап алу критерийлары һәм шартлары авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив-хокукый актында билгеләнә.

11. Субсидияләр Баулы муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнары счетларына күчерелә.

12. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Салих авыл җирлеге бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә Салих авыл җирлеге бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә авыл җирлеге башкарма комитеты һәм районның финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.

Башлык,
Авыл җирлеге Советы рәисе — З. С. Галләметдинов